ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ
ВТ
№ 8–9
27 сентябрь, 2023 ел
РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР
Җир астында – витамин
> 3

СОЛДАТ ХАТЛАРЫ
Бөек Ватан сугышы хатирәләре
> 4

ЙӨЗЬЯШӘР
Эштән курыкмадым, ди Рәшидә Гыймадиева
> 6

Соклану

БӘХЕТ – ҮЗ КУЛЫБЫЗДА

Арча

Өченче мәктәптә укыган вакыт иде. Алтынчы сыйныфта булдык микән, төгәл хәтерләмим дә. Безнең мәктәпкә шундый чибәр, елмаеп кына торган яшь немец теле укытучысы килде. Лилия Нури кызына малайлар гына түгел, кызлар да гашыйк булдык. Ире Барый Каюм улын якыннан белмәсәк тә, читтән торып аннан бераз көнләшә дә идек әле.

Арчалылар беләдер дә, Җиңү паркы каршындагы зур кибет урынында заманында укытучылар тулай торагы иде. Менә шунда кечкенә генә бер бүлмәдә яшәде Бакировлар. Кызлары Гөлнара тугач, аны карарга керә идек. Безгә кызык бит. Аннан яраткан укытучыбызның баласын да күрәсе килгәндер инде. Бер карават, бер өстәл, бер урындык сыя торган бүлмәдә безгә ничек урын табылгандыр. Дөрес әйтәләр шул: күңел киң булсын.

Еллар үтте. Арчада яшәсәк тә, Лилия Нуриевна белән бик сирәк очрашабыз. Ә менә Барый Каюмович җиңел атлетика «короле» буларак спортка бәйле чараларда, ярышларда гел күз алдында булды. 78 яшендә ул, соңгы өч елда гына аларда катнашмый башлаган. Әмма Лилия Нуриевна серне чиште – икесе дә өйдә шөгыльләнә икән. Көн саен иртә, кич берәр километр йөреп кайталар, аннан иртәләрен кырык минутлап физзарядка ясыйлар, тренажерга басалар. Бүген дә гаилә сәламәт яшәү рәвеше алып бара.

> 4

Өлкәннәр тормышы

Эш агачы китерер җимеш

Талны яшьтән бөгәргә кирәк! Элек балалар эшләп үссә, соңгы елларда бу мәсьәләне үз агымына калдырдык. Әмма хезмәттән башка шәхес тәрбияләп булмый.

Күптән түгел Татарстан пенсионерлары (ветераннары) төбәк иҗтимагый оешмасы Теләче районында күчмә утырыш уздырды. Бирелә «Рухи-әхлакый шәхес формалаштыруның нигезе буларак хезмәт тәрбиясе» дигән темага фикер алыштылар.

Бу мәсьәләнең районда ничек хәл ителүе белән танышу Шәтке мәктәбеннән башланып китте. Әлеге мәктәптә укучыларның эштән курыкмаганы күренеп тора. Килеп керүгә, балаларның кул эшләре һәм бакча җимешләре күргәзмәсе каршы алды.

Бергәләп тотынсаң...

Район мәгариф бүлеге методисты Гөлназ Әхмәтвәлиева әйтүенчә, 2021 елдан балаларны профориентацияләү кысасында, Теләче районы ветераннар советы белән берлектә «Эшмәкәрлек дәресләре» проекты эшли башлаган. Район эшмәкәрләре өлкән сыйныф укучылары белән даими очраша, укучылар сәнәгать оешмаларында еш булалар.

– Районның биш мәктәбендә профильле сыйныфлар эшли. Алар социаль-икътисадый, фәнни, технологик юнәлештә укыталар. Узган елдан Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе белән берлектә биш мәктәптә агрокласслар эшли башлады. Теләченең 1 нче балалар бакчасында да рус географик җәмгыяте белән берлектә экологик төркем булдырылды. Безнең балалар белән психологик юнәлештә Арча педагогика көллияте белгечләре шөгыльләнә, – ди Гөлназ Әхмәтвәлиева.

Дәвамы 6 нчы биттә >

Табигать нигъмәте

КИШЕР ДӘВАЛЫЙ

Кишерне табигый даруларның берсе дип тә санап була. Анда С белән В төркеме витаминнары, йөрәк һәм кан тамырлары, шулай ук бөер һәм бавыр эшчәнлеге өчен кирәкле тозлар, микроэлементлар күп. Аны буыннар сызлаганда, бала имезүче хатыннарның сөте кимегәндә, яман шеш авырулары булганда, тын юллары ялкынсынганда ашау да файдалы.

pinterest.com

Көчле ютәлдән интегүчеләргә ярты стакан кишер согына бер аш кашыгы бал болгатып эчәргә була. Салкын тиепме, чүп яки пычрак әйбер эләгеп, күз начар күрә башласа да, ач карынга кишер согы эчәргә кушыла. Эче катып җәфаланучыларга иртән бер стакан кишер согы эчәргә тәкъдим итәләр. Ләкин кеше арасына барасы яки җәмәгать транспортында юлга чыгасы булганда моны сакланып эшләү яхшы. Чөнки бу сок кинәт кенә тәэсир итеп, уңайсыз хәлдә калдыруы бар.

Әгәр дә җәрәхәтләнгән урынга кишерне төеп япсаң, яра тиз төзәлә, яшь ит үстерә. Кишер орлыгы да дәвалау үзлекләренә ия. Бер чәй кашыгы кишер орлыгын ярты литр суда кайнатып төнәткәч, көнгә 3–5 тапкыр яртышар стакан эчкәндә, бөердән ташлар кудырыла. Авыздан ис килүчән булганда да кишер ашау яисә согын эчү файдалы. Әмма уникеилле эчәк җәрәхәте белән җәфаланганда кишерне саграк кулланырга кирәк.

Пешергәндә кишернең файдасы югалмый, яшелчә С витаминын күп югалта, тик шул ук вакытта анда А һәм Е витаминнары яхшы сакланып кала. Тик шуны истә калдырырга кирәк: А витаминны – майда эрүчән витамин. Организм аны үзләштерсен өчен, кишерне май белән бергә кулланырга кирәк. Шуңа күрә чи кишерне үсемлек мае яки каймак белән бергә ашарга киңәш итеплә.

Хикмәтле бәрәңге

Бәрәңге согын көнгә 3 мәртәбә ашар алдыннан эчсәң, файдасы зур. Бәрәңге согы 10 минут эчендә бозыла. Аны сыгу белән эчәргә кирәк.

Бәрәңге согында иммунитетны яхшырта торган С витамины бар. Икегә аерылган юка чәчләрне шулай ук бәрәңге согы белән дәвалыйлар. Аны чәч төбенә сылап, 20 минут тотыгыз да юып төшерегез. Коры бит тиресен бәрәңге согына манылган мамык белән дымландырыгыз. Бәрәңге согы йөрәк өчен дә файдалы, ул холестерин күләмен киметә. Гастрит вакытында бәрәңге согын ун көн эчеп, ун көн тәнәфес ясарга кирәк. Иртән ашарга ярты сәгать кала аны бер стакан эчәргә кирәк. Бәрәңге согы бавырны һәм үт куыгын агулы матдәләрдән чистарта. Аны еш эчкәндә, ашказаны-эчәклек тракты эшчәнлеге дә яхшыра. Гастрит, колит авырулары – 4–5 атна эчендә, ашказаны җәрәхәтен 6–8 атна эчендә бетерә.


depositphotos.com

Яшь бәрәңге согы аеруча файдалы. Тәмле булсын өчен аңа бал йә мүк җиләге согын кушалар.

Витаминнарга бай

Кәбестә яфрагында файдалы матдәләр, аминокислоталар, углеводлар, майлар күп. С витамины, бәрәңге белән чагыштырганда, илле мәртәбә күбрәк! Бу витамин хәтта кәбестәне эшкәрткәндә дә юкка чыкмый, ә бер елга кадәр саклана.

Кәбестә йөрәк чирле кешеләргә, ашказаны җәрәхәтеннән (язва) интегүчеләргә файдалы, азканлылык булганда хәл кертә, фурункулез (чуан-сызлавыклар), экзема белән чирләүчеләргә дә әйбәт. Кәбестәдә эчәклек эшчәнлеген яхшыртучы клетчатка бар, ул атеросклерозга каршы торырга да ярдәм итә. Шулай ук С, В, D, K, E һәм U (латин телендәге «улькус» – җәрәхәт сүзеннән) витаминнарына бай. У витамины ашказаны җәрәхәтеннән һ.б.ш. чирләрдән котылырга ярдәм итә. Аңарда алма, лимон, кузгалак, кумар, фолий кислоталары да күп. Кеше яшәеше өчен үтә дә мөһим булган әлеге файдалы матдәләр туберкулез таякчыгына, стафилококк һ.б. авыру тудыручы микробларга үтергеч тәэсир ясый. Составындагы йод симерүгә бирешмәскә булыша. Кәбестә ашау сөяк авырулары булганда, акыл ягыннан һәм физик йончыганда бик файдалы. Япониядә нурланыш чиреннән интегүчеләр рационына да кәбестә кушалар.



Нияз Бишбалта

ҖАВАПЛАР

Горизонталь буенча: коала, алка, кок, талу, маршал, кобра, аяк, кыр, Юта, азан, атака, кружка, макака, панда. **Вертикаль буенча:** кармак, кама, аек, зар, баржа, наждак, аклама, Панама, акта-ру, аю, ятак, аел, агу, аждаһа, акыл.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Марат ХӘБИБУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

БӘХЕТ – ҮЗ КУЛЫБЫЗДА

< Ахыры. Башы 3 нче биттә

Башта аларга багышланган анкета нигезендә генә язарга уйлаган идем. Әмма алай «салкын» чыгар кук тоелды. Һәм өйләренә киттем. Көтмәгәндә килеп кергән «кунак»ны аптырап та, шатланып та каршы алдылар. Лилия Нуриевна, чәй өстәле әзерлим, дип борчылып йөри башлады. Очрашу сәбәбен аңлаткач кына, эш беткәчкә калдырып, түргә дәште. Аның әле дә шундый чибәр, яшенә караганда (76 яшь) күпкә яшь булуына игътибар иттем. «Барый Каюмович сөйләсен, мин тыңлап утырам», – диде ул, ягымлы карашын иренә төбәп һәм аны иңнәреннән кочып. Аларның үзара мөнәсәбәтләрен аңлау һәм соклану өчен шушы бер мизгел җитте. Кешегә күрсәтү өчен үзеңне шулай тотып булмый. Ирле-хатынлы Бакировларның бу вакытта күзләрендә бер-берсенә карата мәхәббәт, ихтирам, хөрмәт ярылып ята иде. Елмаеп куйдым. Сөйләшүебез дә рәсми түгел, җылы, күңелгә рәхәт килеп чыкты.

Өч сум акча бирәләр иде

Барый Бакиров тумышы белән Апас районының Чирү авылыннан. 1946 елда алты балалы гаиләдә туа. Әнисе башлангыч сыйныфлар укытучысы була. Әтисе Фин, Бөек Ватан сугышларында катнаша, Ленинград блокадасын үтә, 1942 елның язында култык таягы белән өенә кайта. Хисапчы, колхоз рәисе урынбасары, клуб мөдире булып эшли. Барый кечкенәдән утын шакмаклары, терлекләргә үлән әзерләп, ат көтүе көтеп үсә, соңрак ат җигеп эшли. Авылда дүрт ел укыганнан соң, көн саен биш километр ераклыктагы күрше авыл мәктәбенә йөреп белем ала. Икенче авылда урта мәктәпне тәмамлый. Буага барып, ветеринария техникумына укырга керә.

– Тулай торакта яшәдек. Үзебез ягабыз, чиратлап ашарга пешерәбез. Авылдан өч сум акча биреп җибәрәләр. Кырык тиене юлга китә, атна буе саклап кына тотасың, әниләргә күчтәнәч алырга да бераз кала әле. Кайтканда товар поездына утырабыз. Качып кына кайтабыз инде. Әнә шулай укыдык. Тәмамлагач, Апаста ветлечебницада эшләдем. Аннан армиягә киттем, – диде Барый Бакиров, ул елларны искә алып.

Харьковка эләгә ул. Сержантлар әзерләү мәктәбендә алты ай укый. Аннан Одессадан 40 километр читтәге хәрби шәһәрчектә хезмәт итә. «Котовский торган казармада яшәдем», – ди. Спорт клубына йөри, хәрби өчтөрлелек (автоматтан ату, граната ыргыту, каршылыклар полосасын үтү) буенча ярышларда катнаша, призлы урыннар яулый.

Кызларга карамады да

– Җыелма командага аласылар иде. Әмма мин, укыйсым бар, дип кайтып киттем. Казанга педагогия институтының физкультура факультетына укырга кердем. Студентлар профсоюз комитетын җитәкләдем, – дип сөйләде Барый Каюмович.

– Дүрт ел институтның мактау тактасында торды ул, – дип сүзгә кушылды Лилия Нуриевна. – Мин чит телләр факультетында укыдым. Шулай ук профсоюз комитеты җитәкчесе идем. Киңәшмәләрдә очрашабыз. Гел яза. Аны «вундеркинд» ди торган идек. Кызларны күрми дә, аларга карамый да. Аны мин күрдем. Бер киңәшмәдән соң мине озатып куйды. Очраша башладык. Йөреп киттек. Мин бер ел алдан укуны тәмамлап, үземнең авылга эшкә кайтып киттем. Ул, диплом алгач, мине сорарга килде. Шуннан бирле без бергә.

Лилия Бакирова Әгерҗе районының Ямурза авылыннан. Ике бала үсәләр. Әтиләре – шулай ук сугыш ветераны. Яраланып кайткач, колхоз рәисе итеп куялар. Әнисе хисапчы була. Аннан әтисен Красный Бор авылына урман хуҗалыгына эшкә җибәрәләр. Биш яшенә кадәр русча белмәгән кызга башта авыр була. Балалар бакчасына йөреп кенә телне белә башлый. Мәктәпне көмеш медальгә тәмамлый. Казан педагогия институтына укырга бер имтихан биреп кенә керә. Башта фатирда яши, аннан очраклы рәвештә чаңгы ярышы вакытында декан белән таныша. Дөресе, аның декан булуын да ул соңыннан гына белә.

– Трамвайда кайтканда да ул иптәш кызым белән минем янга туры килде. Чал чәчле өлкәнрәк яшьтәге кеше. Кайсы курстан булуыбыз белән кызыксынды. «Без таныш булмаган кешеләр белән сөйләшмибез», – дип җавап бирдем аңа төксе генә. Икенче көнне аны институтта күреп, декан икәнен белеп котым алынды. Үз янына да чакырып алгач: «Беттем. Куачак мине институттан», – дип уйладым. Әмма ул чаңгы ярышында беренче килүем өчен мактады, кайда яшәвемне сорашты, соңыннан тулай торакка урнашырга ярдәм итте.

Арчага юл

Алар республиканың ике почмагыннан. Арчага ничек килеп чыкканнар?

– Ягъфәр Шәмиев белән Габделхәй Фәйзрахманов, бер кеше кирәк, дип институтка килгәннәр. Декан мине тәкъдим иткән. Менә шулай Арчага педагогия училищесына килеп урнаштым. Аңа да 51 ел үтте инде. Аннан Лилия дә училищега укытырга килде. Аңарчы ул мәктәптә иде, – диде Барый Бакиров.

Бу чор эчендә ул «Татарстан Республикасының атказанган физик тәрбия хезмәткәре», халык мәгарифе отличнигы, югары категорияле укытучы һәм башка исемнәргә лаек була, Россия Президенты Владимир Путинның Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Лилия Бакирова да – Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең халык мәгарифе отличнигы.

Әмма аларның иң зур байлыклары – балалары, оныклары. Алар да педагог һөнәрен сайлаган. Гөлнаралары педагогика фәннәре кандидаты, Арча сәнгать мәктәбе җитәкчесе, Ленизалары университетта укып, рус теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеген алып чыккан. Оныклары Рената – немец һәм инглиз теле укытучысы, Эмилия – булачак филолог, Карина унынчы сыйныфта укый, чит телләр белән кызыксына.

Гаилә бәхетенең сере бер-береңне аңлап, кирәк чакта сабыр булып, яратып, кешене ничек бар, шулай кабул итеп яшәүдә, дип саный Лилия һәм Барый Бакировлар.

Гөлсинә ЗӘКИЕВА

ОЛЫГАЕРГА ВАКЫТ ЮК

Апас

Рафаэль абый Солтанбеков – Апас районы тарихында матур эз калдырган җитәкчеләрнең берсе. Тирән белемле, тәҗрибәле, сабырлык һәм итагатьлелек үрнәге булып тора ул.

Рафаэль абый Кайбыч авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килгән. Әтисе Фатыйх озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән, районның күренекле шәхесе, РСФСРның атказанган укытучысы исеменә лаек кеше. Әнисе Факия апа да укытучы була. Ләкин көттереп кенә дөньяга килгән өченче баласын калдырып, якты дөньядан вакытсыз китеп бара.

Әни назы, кайгыртуы җитмәү Рафаэль абыйның күңеленә боеклык өстәсә дә, балачак хыялларының, яшьлек омтылышларының чынга ашуына, максатларына ирешүгә киртә булмый. Кечкенәдән белемгә омтылучан, башлаган эшне азагына җиткерергә өйрәнгән Рафаэль абыйга әтисе һәрчак терәк була, этәргеч бирә, үсендереп, көч һәм ышаныч өсти.

Рафаэль абый Зур Күккүз мәктәбен «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Башкалада энергетика техникумында укый. Хәрби бурычын Амур өлкәсендә үти. Хезмәт юлын мелиорация өлкәсендә башлап җибәрә. Биредә мастер, прораб булып эшләп, җитәкче дәрәҗәсенә күтәрелә. Шушы елларда читтән торып авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый.

Максатчан, яшь белгечне тиз күреп алалар. 1983 елда аны КПССның район комитетына чакыралар. Биредә инструктор, партия комиссиясенең рәисе булып эшли.

Замана белән бергә атлаучы, алдынгы карашлы, килер көнгә үз фикере, карашы булган Рафаэль абыйны 1990 елда район хакимиятенең оештыру бүлеге җитәкчесе итеп куялар. Аннан аппарат җитәкчесе вазыйфасына, 2000 елда исә район Советы рәисе урынбасары итеп билгеләнә. 2009 елдан лаеклы ялга чыкканчы, 4 ел дәвамында хезмәт һәм мәшгульлек үзәге җитәкчесе вазыйфасын башкара.

Кайсы гына вазыйфада булса да, Рафаэль абый райондашларга хөрмәтен югалтмый, кул астында эшләүчеләрне аңлый, аларга үсәргә, яңа дәрәҗәләргә күтәрелергә мөмкинлек бирә.

– Хезмәт елларымны сагынып искә алам. Ничек кенә җаваплы булса да, яратып эшләдем, гомер юлын нәтиҗәләр белән уздым, – ди Рафаэль абый.

Төгәл, бар җирдә тәртип яратучы Рафаэль абый лаеклы ялга чыккач та үзенә шөгыль таба. Ул бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнә. Китап уку – аның иң яраткан шөгыльләренең берсе. Китапханәдә ул иң күп китап укучы булып санала.

Гаиләсендә дә үрнәк, акыллы ир, кайгыртучан әти, таләпчән дәү әти Рафаэль абый. Тормыш иптәше Нәҗия апа белән 46 ел парлы гомер кичереп, кызлары Эльмираны үстерделәр. Аңа ике югары белем алырга ярдәм иттеләр. Кызлары бүген банк системасында эшли. Оныклары Сөләйман – Рафаэль абый белән Нәҗия апаның шатлыгы да, юанычы да.

– Олыгаерга вакыт юк әле. Яшьләр янында без яшьләрчә, тиңдәшләр янында акыл туплаган фикердәшләрчә, – ди Рафаэль абый, елмаеп.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

Фәнис ЯРУЛЛИН

«Син киттең дә...»

Син киттең дә
күңелем буп-буш калды,
Бөтен яме бетте дөньяның.
Канатлары сынган кош шикелле,
Бәргәләнде ап-ак хыялым.

Төн елгасын йөзеп чыга-чыга,
Көчем бетеп, арып егылдым.
Ярда син юк, әкрен генә үксеп,
Ялгыз талга барып сыендым.

Салкын җилгә күкрәгемне ачтым:
– Суытыгыз минем йөрәкне.
Җилләр кинәт кайнарланып китте,
Өтеп-өтеп алды күкрәкне.

Иренемдә елмаюлар сүнде,
Йөзләремнән качты яктылык.
Күңел кылы, өзелә-өзелә диеп,
Бар көченә куйды тартылып.

Ә бит юкса шаярудан гына
Киткән кебек идем кабынып.
Хыяллардан учак яга-яга
Яшәрмендер, ахры, сагынып.

Яшерен хәзинә

Безнең сөю яшерен хәзинәдәй
Тирән казып җиргә күмелгән.
Белмәсеннәр өчен өсләренә
Тигез итеп туфрак сибелгән.
Һәм белмәс тә аны һичбер кеше,
Ул күмелгән шундый тирәнгә.
Өсләрендә уйный бала-чага,
Ауный-ауный яшел чирәмдә.
Бәлки анда беркөн мәйдан булыр,
Сабан туе үтәр гөр килеп.
Чабып үткән атлар тоягыннан
Очкын гына калыр сирпелеп.
Пар гашыйклар бәлки утырыр
шунда,
Йөрәкләре коштай очыныр.
«Чулт-чулт» иткән үбешү тавышына
Былбыл сайраулары кушылыр.
Ул гашыйклар сөю шатлыкларын
Беркемнән дә тормас яшереп.
Күлүләре, алтын тәңкә булып,
Аланнарга китәр чәчелеп.
Безнең хәзинәбез калыр җирдә,
Табалмаслар – үтәр заманы.
Күпме хәзинәләр котәләрдер
Хуҗалары казып алганны.
Безнең хәзинә дә калыр җирдә
Беркем белми торган сер булып.
Сокланырлар аңа, җир өстенә
Калкып чыкса гына гөл булып.

Туган ягы кирәк кешегә!

Читтә йөргән чакта, сагындырып,
Керер өчен төнлә төшенә,
Зәңгәр таңлы, биек аяз күкле
Туган ягы кирәк кешегә.

Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә,
Шатлыкларын ишеттерер өчен,
Туган ягы кирәк кешегә.

Йөри-йөри күңеле тупасланса,
Тузан кунса яшьлек хисенә,
Бер сафланып килер өчен тагын
Туган ягы кирәк кешегә.

Яшәр өчен бетмәс көч алырга
Олысына һәм дә кечегә,
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә.

Парлы гомер

Зәй

Тормыш киңлекләрен иңләп, куйган максатларга ирешеп, зур тормыш мәктәбен үткән өлкәннәр күп безнең районыбызда. Шундыйларның берсе – Дүртмунча авылында гомер кичерүче, бу көннәрдә 90 яшен тутырган Фәүзия Хуҗина.

Тормыш иптәше Миннегариф абый белән бергә гомер итүләренә – 64 ел. Уллары Назиф, киленнәре Индира белән төп нигездә бәхетле картлык кичерәләр. Менә шундый дус, тату, ярдәмчел гаилә бөтен авылга үрнәк, балалары-оныкларының гына түгел, ә барлык якыннарының горурлыгы булып яши.

Миннегариф абый 1934 елның 6 мартында Сарман районы Шыгай авылында якты дөньяга килә. Әтиләре сугышка киткәч, бабалары үзләренә Дүртмунча авылына яшәргә алып кайта (әнисе Дүртмунча авылы кызы була). Фәүзия апа – Сарман районы Сарысаз-Тәкермән авылы кызы. Шушы якларга урман кисәргә килгәч кавыштыра аларны язмышлары.

Икесе дә тугызынчы дистәләрен вакладылар. Әмма аларга бу яшьне биреп булмый әле. Икесе дә җитез, тынгысызлар, йөзләреннән елмаю китми. Ә бит тормыш юллары җиңел генә булмаган. Бүгенге тормышларына шатланып туя алмаган Хуҗиннарның сугыш елларына туры килгән балачагы-яшьлеге бер дә кызыгырлык түгел.

Хуҗиннар гаиләсендә өч малай үскән. Миннегариф абый гомер буе колхозда механизатор булып эшли. Ул гомеренең 40 елын яраткан хезмәтенә багышлый. Фәүзия апа колхозда бригада эшчесе була.

Хәзерге көндә улларының барысының да үз гаиләләре бар, әти-әниләре кебек матур итеп гомер итәләр. Миннегариф абый белән Фәүзия апа – бик бәхетле әби белән бабай: 5 оныкларын, 7 оныкчыкларын сөяләр.

Фәүзия әбине 90 яше белән Дүртмунча авыл җирлеге башлыгы Радик Ситдыйков, район мәдәният йорты каршында эшләүче автоклуб хезмәткәрләре өенә барып котлады. Юбилярга котлау сүзләре яңгырады һәм аның хөрмәтенә матур җырлар башкарылды.

ДӨРЕС ИТЕП ЯШӘСӘҢ...

Зәйдә яшәүче Хәмдия апа белән Кафил абый Хисамиевлар күпләр өчен үрнәк булып тора. Алтмыш дүрт ел тормыш юлында шатлыкларын да, авырлыкларын да бергәләп кичергәннәр. Бер-берсенә кирәк, терәк булганлыктан, гаилә корабы язмыш дулкыннарында челпәрәмә килмәгән.

Кафил абый белән Хәмдия апа ислам кануннары буенча яшиләр: ураза тоталар, биш тапкыр намаз укыйлар, игелекле эшләр башкаралар.

Кафил абый Имәнлебашта туып-үскән, ә Хәмдия апа – Кәдек авылы кызы. Алар кичке уенда танышалар. Зәй яшьләре эштән соң Островский белән Тәзүчеләр урамнары кисешкән урында «пятачок»ка җыела торган була. Кафил, гармунчы буларак, түгәрәк уенның йөзек кашы була инде.

– Мин Зәйгә 1957 елда төзелештә эшләргә килдем. Ул елларда Зәй бистәсе, ГРЭС төзелеше республика гына түгел, аннан читтә яшәүче егет-кызларны үзенә җыйды. Бирелә мәктәпләр, район үзәк дәваханәсе, йортлар төзүдә катнаштым. Аннан мин хезмәт куйган оешманы ГРЭС төзелешенә чакырып алдылар. Станциядә иң беренче арматураны коюга без эшләгән бригада алынды. Электр станциясенең алтынчы блогын куйганчы биредә эшләдем, – дип сөйли Кафил абый.

Хәмдия апа шулай ук ГРЭС төзелешендә, озак вакыт сәүдә тармагында хезмәт куя. Хисамиевлар «Шанхай» микрорайонында үз йортларын төзиләр.

Кафил ага – Түбән мәхәллә мәчетенең актив әгъзасы. Ул – мәҗлесләр, исем кушу йолалары, никахлар вакытында хөрмәтле кунак. Шулай ук мөселман йолалары буенча соңгы юлга озатырга да чакыралар аны.

Хисамиевлар гаиләсендә өч бала үсә: Равил, Равия һәм Ильяс. Хәзер алар оныклар һәм оныкчыкларын тәрбияләргә ярдәм итәләр.

– Балалар, кияү-киленнәр, оныклар – барыбыз бергә җыелганда, 27гә тулабыз. Бәхетле картлык кичерәбез. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән ышанып, шәригать кануннары буенча яшәсәң, барысы да килеп чыгачак, – ди Хәмдия апа.

Клара ЕРМОЛАЕВА

ЭШ АГАЧЫ КИТЕРЕР ҖИМЕШ

«Яшь буынны эш белән тәрбияләп була», – ди район башлыгы.

Балалар шаккатырды.

< Ахыры. Башы 3 нче биттә

Мәктәп директоры Александр Ибушев та балаларны эшкә өйрәтү яклы. Аларның мәктәбен тәмамлаган укучылар нинди эшкә тотынса, шуны башкарып чыга икән.

– Яшьләрне авылга кайтару проблемасын ничек тә хәл итәргә иде. Укучыларның авылга кайту максаты белән укырга киткәннәре дә ахыр чиктә әйләнеп кайтмый шул. Авыл өчен кирәкле булыр дип сайланган очракта да, күп җирдә андый белгечләргә ихтыяҗ булмаска мөмкин. Шуннан соң безнең алга мәктәпне тәмамлаучыларны авылдан читкә җибәрмәү, ә аларны тормыш алып барырдай, авыл хуҗалыгында эшләүче яңа буын эшмәкәрләре, фермерлар итеп тәрбияләү бурычы килеп баса, – ди ул. – Мондый шәхесне мәктәп бары тик укыту-тәрбия процессы белән хезмәт практикасы эшчәнлегенең тыгыз бәйләнеше аша гына тәрбияли ала. Барлык яктан формалашкан шәхес тәрбияләү турында күпме генә сөйләсәк тә, нинди генә махсус программалар әзерләнсә дә, төп тәрбияче булып хезмәт тора.

Шәткедә эшләп үсүнең ни икәнен яхшы беләләр. Узган уку елында укучылар көче белән 3 тоннадан артык уңыш үстерелгән. Шәтке мәктәбе инде берничә ел куян үрчетү белән шөгыльләнә.

Александр Ибушев килгән кунакларга музейларын да күрсәтте, эшкә уңган балалар белән дә таныштырды. Укучыларның кул эшләрен дә барыбыз да бик ошаттык. Өлкәннәр карвинг, токмач кисү, сувенир түбәтәйләр һәм калфаклар тегү, хәтта парикмахер сәнгате буенча мастер-класслар да карадылар.

«Теләче» сәнәгать паркы 2012 елда ачылган. Биредә 45 кеше хезмәт куя. Уртача хезмәт хакы – 45 мең сум. Әлеге оешманың сарымсак үстерә торган үз кырлары бар. Күршедә генә пластик эшкәртү заводы эшли. Биредә калдыкларны эшкәртеп, көнкүреш кирәк-ярагы ясап чыгаралар. «Богородские розы» теплицасына килеп кергәч, бөтенләй шаккаттык. Баксаң, кечкенә генә Теләчедә ел дәвамында чәчәк һәм гөлләр үстереп саталар икән.

Гаиләдән дә тора

Очрашуның төп өлеше район мәдәният йортында узды. Татарстан ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков, хезмәт тәрбиясе турындагы теманы беренче ел гына күтәрмибез, ди.

– Балаларны хезмәткә җәлеп итү турында өлкәннәр күп тапкыр искәртте. Вакытында эшкә өйрәтмибез, кадерле вакытны әрәм итәбез, дип тә әйтеп карадык. Хезмәт тәрбиясе кирәк, дип чыгышлар ясадык. Мәсьәләне хәл итү юлларын да күрсәттек. Тик безне ишетергә теләмәделәр, – ди Хәбир Иштирәков. – Хезмәт тәрбиясе мәгариф оешмаларында түгел, гаиләдән үк башланырга тиеш. Хәзер бит бик күпләр баласын эшкә өйрәтми. Соңрак, балам эшләми, дип зарлана башлыйлар. Соң булса да, хезмәт тәрбиясенең бик кирәк икәнен аңладык. Шөкер, боз кузгалды.

Сүз уңаеннан, былелның 1 сентябреннән укучыларны җәмгыятькә файдалы хезмәттә катнаштыра башлаячаклар. Алар мәктәп яны территориясендә агачлар яки чәчәкләр утырта, мәктәп мәйданчыгын яки сыйныфны бизи, театр костюмнары әзерли, музейда яки китапханәдә ярдәм итәчәкләр. Укучыларны, ата-аналарының ризалыгыннан башка, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, эшкә өйрәтә алачаклар.

Теләченең ветераннар советы рәисе Рәис Заһидуллин районда яшәүче өлкәннәр тормышы белән таныштырды. Районда 13364 кеше яши, шуларның 4 меңнән артыгы – өлкән яшьтә. Теләчедә өлкән яшьтәге 3 фронтовик, 84 тыл хезмәтчәне, 5 Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары яши. Авыл җирлекләрендә 14 беренчел ветераннар оешмасы эшли икән.

– Без балалар белән еш очрашабыз. Эшкә өйрәнеп үссеннәр өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Юкка тырышмыйбыз бит, – балалар тормышта үз урынын тапсын, ашлы да, эшле дә булсын дибез, – ди Рәис Заһидуллин.

Фоторепортажның дәвамы >

Рифкать Шәфыйков ясаган музей.

Шәтке урамы моңга күмелде.

«БУ МИНЕМ АКТЫК ХАТЫМ БУЛМАГАЕ»

«Татарстан ветераны» кушымтасында Бөек Ватан сугышында катнашкан солдатларның хатларын тәкъдим итәбез. Әлеге истәлекләрне редакциягә КФУ профессоры ***Марсель БАКИРОВ*** *тапшырды.*

< Дәвамы. Башы алдагы санда

Актаныш районының Тәкмәк авылыннан сугышка алынган Габсаттарның язмышы шулай ук бөтенләй көтелмәгән, гадәттән тыш шартларга туры килгән үлем белән тәмамланган. Бу турыда аның әнисе Сорур апага улының фронтташ иптәше, Балтач районының Түбән Кенә авылы егете Габдуллаҗан Гыйззәтуллин язып җибәргән. Фронттан килгән тетрәндергеч хәбәрнең анага ничек тәэсир иткәнлеген күз алдыбызга китерик. Мондый үзәк өзгеч фаҗигане барысына да түзә торган ана йөрәге генә күтәрә ала торгандыр. Шул хаттан өзек китерәбез.

13 август, 1944 ел

«Хөрмәтле Сорур апа! Синең газиз улың Габдуллаҗан минем белән бер частьтан иде. Мин үзем командирларны туйдырып торам. Татарлардан миннән кала улыгыз берүзе генә булгач, мин аңа ипи, ит-май, боткалар биреп ашата идем. Башта дивизиядә биш татар булса да, өчесе үлгәч, без аның белән икәү генә торып калдык. Андый-мондый булсам, әнигә хат язарсың дип, ул миңа үзенең адресын бирде. Менә инде шул адрес буенча, бик авыр булса да, сезгә кайгылы хәбәр белдерергә туры килә.

10 август көнне, Сорур апа, синең газиз улың иртәнге сәгать 6да вафат булды. Алар бер рус солдаты белән икесе окопта күзәтче-дозор булып утыралар иде. Өсләренә снаряд төшеп ярылды.

Габдуллаҗанның башын гына таба алдык. Аның канлы башын күкрәгемә кысып, үкерә-үкерә еладым. Аннары тирән чокыр казып күмдем.

Сиңа бу хәбәрне ишетү, белем, бик авыр булачак инде, Сорур апа. Никадәр генә авыр булса да, түзәргә тырыш, бик елап үзеңне бетермә. Бер сиңа, аерым гаиләгә генә түгел, ә бөтен ил өстенә килде бит зур кайгы».

***

Актаныш районының Зур Бирәзә авылында туып-үскән Сәлах Хәсәнов та сугышның беренче көннәреннән үк фронтка җибәрелә. Үзенең хәләл җефете Гөлбаһарга ул сагыш һәм мәхәббәт белән тулы хатлар яза, шулай ук үзе турында да хәбәр итә. Язганнарыннан аның гаҗәеп эмоциональ кеше булганлыгы, хатыныннан аерылып ут эчендә йөрүне бик авыр кичергәнлеге беленеп тора. Шулай ук исән калмаячагын алдан ук бөтен күңеле белән сизенүе дә игътибарны җәлеп итә. Нәкъ менә ифрат хисле булганга күрә дә, иртәгә сугышка керәсе дигән көнне ул таң тишегеннән торып соңгы хатын яза һәм хәтта хис-тойгыларны үзенчә, ягъни үзе булдыра алганча, шигырьгә сала. Аның уяныр алдыннан гына күргән төше һәм аны үлемгә юраганы соңыннан чыннан да юш булып чыга. Менә Салихның шул хакта сөйләүче үзәк өзгеч хатлары.

7 июль, 1941 ел.

«Сәлам язам, иркәм, сиңа ерак илләрдән,
дары төтене баскан җирләрдән.

Шулай итеп, җаным Баһар, дөньялар бозылды да китте, һәр минут саен сугышка керү хәбәрен көтеп торабыз. Сугыш башланганнан бирле өстәл янына утырып ашаганыбыз, ике-өч сәгать тынычлап йоклаганыбыз юк.

Сугыш өчен бөтен кирәк-яракларны алдык. Башка кигән тимер эшләпә башны түбәнгә баса да тора, җаным. Каенсар егете Зарипов һәм башка танышларым икенче частька күчтеләр. Ротада районнан берүзем генә калдым инде. Танк пулеметчысы итеп билгеләделәр, пехотада да пулеметчы була аласың, диделәр. Танклар безнең пушкаларны да тартып йөри. Башта үзебез өстери идек.

Их, моңлы итеп бер җырлыйсы килә. Кайбер чакта күзгә яшьләр килә. Кайтып, туган илләремдә яшәрмен, дип әйтеп тә булмыйдыр инде, җаным. Әниләр янына барып, хәлләрен белешеп тор, туганнар белән дә бәйләнештә тор, яме!

Гөлбаһар иркәм, минем төсем, истәлегем итеп «Яңа карурман» җырын җырла. Җае чыкканда, сезне искә төшереп, мин эчтән генә гел шул җырны көйләргә тырышам.

Дошман бик көчле, җаным. Җиде көн эчендә безнең яктан 15 мең солдат үлгән, диделәр. Киләсе атнада булачак корбаннар эчендә минем булуым да бик мөмкин. Безнең совет халкы җиңәргә тиешле, ләкин явыз дошманны бездән соңгылар җиңәрләр».

***

21 июль, 1941 ел.

«Сөйкемлеләрдән сөйкемле, кадерлеләрдән кадерле Гөлбаһар! Сиңа бәлки бу актык сәламем һәм соңгы хатым булыр. Бу соңгы сәламемне гомерең буена сакларсың дип өметләнәм. Иртәгә без сугышның иң куәтле урынына китәргә тиеш. Кулымда – көчле пулемет, күңелемдә – син. Әгәр мин туган җиремә исән хәлдә әйләнеп кайта алмасам, киноларда пулемет күрсәң, сине өзелеп сөйгән, ләкин гомере вакытсыз өзелгән Сәлахыңны искә төшерерсең.

Әйе, син инде миннән калырсың, иркәм, бүген төнлә бик начар төш күрдем. Өстемдә кара кием, башымда кара түбәтәй икән. Янымда иптәшләрем дә бар. Үзем бертуктаусыз күләм дә җылыйм икән. Күңелем сизенә: син бу хатны алганда, минем исән булуым бик икеле, чөнки без иртәгә бик каты сугыш барган урынга чыгып китәбез. Бөтен кирәк әйберләрне вагоннарга төядек инде. Ичмасам, кызым да исән калмады. Син аны минем төсем итеп тәрбияләгән булыр идең.

Фронттан, сугыш барган яктан җәрәхәтләнеп, ранен булып кайтучыларның исәбе-хисабы юк, шундый күп. Әгәр мин дә ранен булып кайтсам, кабул итәрсең бит, җаным? Ләкин, нигәдер, исән калуыма күңелем ышанып бетми. Бу минем актык хатым булмагае. Хуш, бәхил бул, минем сөеклем.

Хат язучы Сәлахың».

***

Әлекке Тархан (хәзерге Тәтеш) районының Чурапан авылыннан ил өстенә килгән сугыш афәтен баштан ук үз җилкәсендә татыган Әхмәт Ситдыйковның хаты да бәхилләшү характерында. Колхозда бригадир булып эшләгән бу биш бала атасының (алтынчы баласы әтисе һәлак булгач туа) ут эченә керер алдыннанниләр кичерүе бердәнбер хатында сакланып калган. Үлеме алдыннан да ул үзеннән бигрәк гаиләсе өчен борчылган. Аларга соңгы әманәтен, васыятен язып калдырган.

4 октябрь, 1941 ел.

«Сезне бик тә якын күргән иптәшем Аҗар (хатынының тулы исеме Бибихаҗәр), сиңа якын иптәшең Әхмәтшадан бик сагынычлы күп сәлам һәм дә, биш балам, йөрәк бәгырьләрем, бишегезгә дә бик каты сагынып, бер күрергә зар булып, күп сәламнәремне озатып калам.

Сәлам соңында – үзебез исән-сау, вагонда каты сугышлар барган якка китеп барабыз, Мәскәүдән ике станса уздык инде. Андагы тормышны мин белеп бетермим. Аҗар, терлекләреңне суйдырып, итеңне күбрәк бәрәңге белән пешерә торган бул. Икмәкне саклап тот. Акча кирәксә, бер-ике потын сата да аласың. Калганнарын үзең карарсың.

Безнең кайтулар икеле. Үтә бәхетле булсак кына кайта алырбыз. Тирә-күршеләр бар да бәхил булсыннар. Бүген 4 октябрь. Синнән аерылганнан бирле, Аҗар, күземнән яшь кипкәне юк әле. Аерылу бик авыр булды. Аллаһы Тәгалә дөнья шатлыклары бирсен, ахирәт бәхетеңне киң кылсын. Аҗар бәгърем, балаларым, бәхил булыгыз. Бер-берегезне ташламагыз, исән-сау яшәгез. Ләгънәт сугыш яңадан беркайчан да килмәсен.

***

Арада туган ягыннан, якыннарыннан шактый озак вакытлар буена бернинди дә хәбәр-мазар килмәвенә ризасызлык һәм үпкә белдергән хатлар да очрап куя. Сарман районының Мортыш-Тамак авылыннан фронтка киткән Мәхмүрахман Сәлахов хатында, мәсәлән, мондый юллар бар:

«Нишләп бер дә хат салмыйсыз? Үзем әллә ничә хат салдым. Бер хатыгызны да алганым юк. Әллә үлеп беттегезме? Әллә бер бит кәгазегезне җәллисез? Әллә вакытыгыз юкмы? Әллә инде бөтенләй оныттыгызмы? Сез онытсагыз да, мин бер генә минутка да сезне истән чыгарганым юк. Мөгелсемнәрне әйтмим дә инде. Кыш көне 15 айга бер хатларын алган идем, шуннан бирле алганым юк. Алар минем барлыкны бөтенләй исләренә дә төшерми торганнардыр.

Үзегезнең тормышларыгыз ничек? Ашарыгызга бармы? Колхоз икмәк бирәме? Хат язмасагыз да, сорап языйм инде. Мөгыйн кияүдән хат алып торам, хет аның аша булса да исәнлегегезне аз-маз белгәләштерәм».

Дәвамы киләсе санда >

ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Азнакай

Район ветераннар советы рәисенең бик яхшы сыйфаты бар: ул эшләгән кешене күрә белә һәм аны ничек итеп булса да бүләкләргә, сөендерергә тырыша. Гадәттә бу бүләк берәр җиргә сәфәр рәвешендә була. Хәзер «эчке туризм» дигән сүз модага керде. Ә без күп еллар инде эчке туризм белән шөгыльләнәбез, туган ягыбызны өйрәнәбез.

Ашаган белми, тураган белә, диләр. Комфортлы автобуста зур төркем пенсионерларга бер көнлек экскурсия оештыру өчен Миргасыйм Ильяс улы Кәримовка күп мәсьәләләрне хәл итәргә, кабул итүче як белән кат-кат сөйләшергә, бөтенесен уйларга, исәпләргә кирәк булганы көн кебек ачык. Ярый, безнең бәхеттән, районыбыз башлыгы Марсель Шәйдуллин өлкән яшьтәгеләргә тирән хөрмәт белән карый һәм һәрчак ярдәм итә.

Һәр авылда башлангыч оешманың эшен иң яхшы оештыручы (бушка эшләүче!), өлкәннәрне актив тормышка тартучы, төрле конкурсларда, фестивальләрдә җиңүче, ветераннар советының барлык эш-гамәлләрендә терәк һәм таяныч булып торучы 43 пенсионер июль иртәсендә Актанышка юл тотты. Ул якны бик күрәсе килә иде. Ни дисәң дә, Актаныш – Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевне, легендар җырчы Әлфия Авзалованы, данлыклы «Агыйдел» ансамблен биргән төбәк.

Район чигендә безне хуҗалар – башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Дилбәр Әнвәрова, ветераннар советы рәисе Нурулла Нурлыев һәм үзешчән артистлар ипи, җыр-музыка белән бик матур каршыладылар.

Аннан соң без республикабызның йөзек кашы булган "Агыйдел" дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «өе»ндә – филармониядә булдык, яшь артистлар белән очраштык, аларның чыгышларын карадык. Иҗат коллективында 53 кеше икән. Россия төбәкләренә, чит илләргә гастрольләргә чыгалар, концертлар вакытында 24әр бию башкаралар. Һәр биюгә – яңа күлмәк!

Сәфәребез Агыйдел елгасында дәвам итте. Елга буйлап паромда йөздек, ветераннарның «Мирас» ансамбле белән таныштык, бергә җырладык, биедек. Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең туган авылында – Әнәктә дә булдык. Биредәге музеййорт эчтәлекле, зәвыклы булуы, сыйфатлы эшләнеше белән сокландырды, ә аның каршындагы яшь парк заманча дизайны һәм матурлыгы белән җәлеп итте.

Бару-кайту юлларыбыз Актаныш, Мөслим, Сарман районнары аша узды. Күбебез хәзер шәһәрдә яшәсәк тә, без – барыбер җир кешесе. Кайда быел җәй яңгыр яуган, кайда яумаган икәнне күреп, икмәк уңышы, печән нинди буласын фаразлап, басуларны кызыксынып күзәтәбез.

Миргасыйм Кәримов – авыл хуҗалыгын яхшы белә торган кеше. Сөйләп, аңлатып бара. Тарихи фактларга да тукталa.

Ул тынып торган арада гармунчылар инициативаны үз кулына ала. Кулдан кулга күчереп, гармун уйныйлар, җырчыларыбыз җыр суза. Шулай итеп, моң эчендә йөзеп, Татшуганга килеп җиткәнне сизми дә калдык. Ә монда авыл уңганнары чәй әзерләп көтеп тора икән. Җыр-биюле тукталыш бергәләп истәлеккә фотога төшү белән тәмамланды.

Моңлы сандугачыбыз

Үзен белә-белгәннән бирле җырлый ул. Кечкенә генә Кәтем авылында туып-үскән Мәхдүлә күршедәге зур авылда – Кәкре Елгада 8 класс тәмамлаганнан соң дүрт ел колхозда сыер савучы һәм учетчы булып эшли.

Математиканы яратуы, саннар белән эшләргә, исәп-хисапка хирыслыгы аның киләчәк хезмәт юлын билгели: ул сатучылык эшенә күчә, аннан чирек гасырдан артык Азнакайның Сакълык банкында кассир-контролер һәм филиал мөдире вазыйфаларын башкара. Төгәл, гадел, игътибарлы хезмәткәр буларак мактаудан төшми. Мактау кәгазьләренең, рәхмәт хатларының чутсыз булуы шуны дәлилләп тора.

Кешеләр белән җиңел аралашучан, ягымлы, тыйнак һәм сөйкемле Мәхдүлә Латыйп кызы (рәсемдә – уртада)– район һәм шәһәр ветераннар советының иң актив әгъзаларының берсе. Күп еллар ревизия комиссиясе рәисе булды. Шашка-шахмат ярышларында катнашып, призлы урыннар ала. Һәм гомер буе сәхнәдә! Бер концерттан, смотрдан калмый. Җырлый, бии, шигырь сөйли. Моңлы итеп мөнәҗәтләр, бәетләр, догалар укый.

Менә 23 ел инде ул – ветераннарның «Хәтирә» ансамбле солисткасы. Ансамбль белән бергә район авылларында, Актүбәдәге картлар йортында, Азнакай санаториенда еш куелучы концертларда аны һәрвакыт алкышларга күмәләр, кат-кат сорап җырлаталар. Республика күләмендә үткәрелүче «Балкыш» фестивалендә призлы урыннар яулавы, Казан телевидениесендә «Җырлыйк әле» тапшыруында катнашуы, Татарстан Мәдәният министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнүе аның шушы көннәрдә 80 яшен тутырган Мәхдүлә Гуминаның тагын бер казанышы өстәлде: шәһәр үзешчәннәренең йомгаклау тамашасында аңа «Сәхнәгә тугрылык өчен» дигән махсус приз тапшырылды. Иң мәртәбәле җырчыларга тапшырыла торган «Легенда» премиясе кебек кабул иттек без бу вакыйганы һәм чордашыбыз өчен чиксез сөендек. Моңлы сандугачыбыз ул безнең!

Нәсимә КАМАЛИЕВА

Хәрәкәт яшәтә

Апас районының Зур Болгаер авылында туып-үсеп, яшьлеге күмер шахталарында узган, 93 яшьлеген каршылаган Әминә әби Саматованың йорты чәчәкләргә күмелгән. Җор телле, шигъри җанлы, изге догалардан аерылмаган Әминә әби чәчәкләр белән сөйләшеп, серләшеп үзенә яшәү көче ала.

Аның капка төбеннән үк аллы-гөлле чәчәкләр каршылый. Сукмаклар, бакча, ишегалды – бар да чәчәкләргә уралган. Үзенә җитәрлек яшелчәсен дә утырткан.

– Матурлык булсын дисәң, бик күп эшләргә кирәк. Хезмәтне яратам. Шуңа күрә яшимдер дә. Хәрәкәт, матурлык кешене яшәтә дә, яшәртә дә. Ул бер яктан – зәвык, икенче яктан – хәрәкәт. Йоклап ятмыйм. Китап, журналлар укыйм, догалар да өйрәнәм, телевизор да карыйм, урамда да өлгерәм, – ди Әминә әби.

Чәчәк үстерү серләрен яхшы белә, орлыкларны үзе әзерләп, үсентеләрен иртә яздан утырта.

– Җирне тәрбияләргә кирәк. Карамасаң, җир ашатмый. Уңышны алам, урынын артыннан ук казып куям. Җир суларга тиеш. Чәчәк, яшелчәләрнең төпләрен йомшартып торам, чүпләрне гел утыйм. Сәгать белән исәпләшмичә эшлим. Иртән чыгып, чәчәкләрнең хәлләрен сорашам, сөйләшәм, әле шигырьләр дә укыйм. Алар белән ялгызлыгымны да онытам, – ди ул.

Ләйлә ИСКӘНДӘРОВА

РӘШИДӘ ГЫЙМАДИЕВА:
«ТОРМЫШНЫ ЯРАТТЫМ»

Буа

Районда аны белмәгән кеше юктыр. 100 яшьлек Рәшидә Гыймадиева хакында сүз чыкса, күпләрнең олы ихтирамга лаек ветеранга бәйле истәлек-хатирәләре исләренә төшә. Үткән тормыш юлы аның кешеләргә булышудан, яхшылык эшләргә тырышудан гыйбарәт.

Кайбыч районы үзәгендә 1923 елда дөньяга килгән кызга урта мәктәпне тәмамлаганнан соң чыгарылыш кичәсен күрү насыйп булмый. Сугыш башлану хәбәре барлык хыялларны челпәрәмә китерә. Рәшидә белән иптәш кызлары, военкоматка килеп, үзләрен сугышка җибәрүләрен үтенәләр. Сәламәтлеге буенча комиссия уза алмау сәбәпле кызны алмыйлар. Рәшидә бу хәлне бик авыр кичерә, сыйныфташларым арасыннан китүчеләр бар бит, дип үксеп-үксеп елый. Әнисе Хәдичә апа 6 баласының икенче булган кызын үзенчә юата: «Бәбкәм, җиңүне якынайту өчен монда да үз өлешеңне кертә аласың, тылда да эш җитәрлек», – дип тынычландыра.

Яшь кыз район судына сәркатип булып эшкә урнаша, эше буенча читтән торып укырга керә. Судья вазыйфасын алып баручы Рәшидә Халитова декрет ялына киткәннән соң аның урынында судьялыкны алып бара. Бу елларда законнар каты, таләпләр зур. Өйдәге ач балаларына ашату өчен кесәсенә ашлык салып кайтучыларны төрмә көткән бит. Актив комсомолка, комсомолның район бюросы әгъзасы буларак, авылларга йөреп, төрле тикшерү эшләрендә катнаша. Берзаманны мал-туарның кышлавын тикшерү өчен Кайбычтан 18 километр ераклыктагы Шүширмә авылына («Көрәшче» колхозы) җәяүләп юлга чыга. Урман тирәсеннән үткәндә каршында юл аркылы чыгып баручы өч бүрене очрата. Сугыш елларында әлеге ерткычлар бик күп үрчегәннәр. «Каттым да калдым. Нишләргә дә белмим. Ярый әле әлеге җанварлар миңа карап тордылар да үз юллары буенча янәшәдәге елгага таба киттеләр», – дип искә ала ул.

Клуб мөдире Әһлиулла Хәкимуллин җитәкчелегендә авылларга барып лекцияләр сөйләп, концертлар куеп йөриләр. Рәшидә бер чарадан да калмый. Бервакыт Кайбычтан 12 километр ераклыкта Яшел Үзән районының Мамадыш дигән авылында зур концерт күрсәтәләр. Аннан соң дөм караңгыда кайтыр юлга чыгалар. Өйләренә җиткәндә таң беленә башлаган була инде. Бераз булса да йоклап та тормыйча эшенә чыгып китәргә туры килә.

Язгы чәчү, урып-җыю барышын вәкил буларак күз уңында тоту дисеңме, авылларга барып, концерт-спектакльләр күрсәтү, өмәләр оештырумы – берсе дә яшь кыз катнашыннан башка үтми. 1946 елда сугыштан кайткан Федор Гыймадиев белән тормыш корып җибәрәләр. 1963 елда Кайбыч районы бетерелгәннән соң гаилә Буа шәһәренә күченә. Яңа урында Федор Семенович судья вазыйфасын башкара, Рәшидә ике дистә елдан артык партиянең район аппаратында эшли. Һәр вазыйфаны җиренә җиткереп башкаручы Рәшидә Шакир кызы «Кинопрокат»ның районара бүлекчәсенә җитәкче итеп билгеләнә. Халык бу елларда киноларга ябырылып йөри. Кинофильмнарның комиссия тарафыннан үткәрелгәннәре генә тәкъдим ителә. Бүлекчә советына кергән биш районның (Буа, Тәтеш, Чүпрәле, Апас, Кайбыч) кино хезмәте күрсәтүчеләр эшенә квартал саен йомгак ясала. Әлеге җыелышлар Рәшидә Шакир кызы катнашыннан башка узмый. Ул халык теләгән канәгатьләндерергә тырыша.

Бервакыт Рәшидә апа сугыш ветераннары Федор Якушенконы, Галим Шәйхиевне, Имам Хәсәновны да ияртеп, Яңа Чәчкап авылы клубына килде. Монда киномеханик Мөслим Сөбханов хатыны Гөлшат белән җиткерелгән планны ай саен үтәп баралар, бик тырышып эшлиләр иде. Рәшидә апа аларның хезмәтенә зур бәя бирде, кешеләр белән тыгыз элемтәдә торуларын мактады. Мондагы өлкәннәр сугыш темасын яратса, ә яшь-җилкенчәк һинд киноларын яратып карый икән. Рәшидә апа белән килгән кунакларның йөрәккә үтә торган чыгышларын бик бирелеп тыңладылар, һәр чыгыш ясаучыга гөрләтеп кул чаптылар. Авыл советы рәисе Кәшифә Хисамова кино хезмәте күрсәтүнең торышын игътибарда тоткан өчен тамашачылар исеменнән кунакларга рәхмәт белдерде. Җитәкче мондый эчтәлекле очрашуларны авыл саен уздыруны гадәткә кертте. Кешеләрнең өйләрендә телевизор булмаган вакытлар да бар иде бит. Күңел биреп эшләгәч, республикада төрдәш коллективлар арасында барган ярышта «Таткинопрокат» бүлекчәсенең күчмә кызыл байрагын берничә мәртәбә яулауга ирештеләр. Коллектив хезмәте республикада өлге булып саналды. Үзенең төп вазыйфаларыннан тыш та Рәшидә Шакир кызы күп төрле җәмәгать эшләрен җигелеп тартты. Район мәдәният бүлегендә халык контроле төркеме, иптәшләр суды рәисе вазыйфаларын башкарды. Сугыш һәм хезмәт ветераннарының район Советы оештырылганнан соң 1987 елның февраль аеннан бирле озак еллар дәвамында аның җаваплы сәркатибе вазыйфасын үтәде. Ветераннарның район Советы президиумы рәисләре – бүген мәрхүм Василий Яковлев, Рафыйк Хәйбуллов, Николай Дементьев белән уртак тел тапты, сугыш ветераннарының үзләренә тиешле ташламалардан файдалануларын тәэмин итү, тормыш-көнкүрешләрен җиңеләйтү өчен зур тырышлык куйды. Хезмәте дә югары бәяләнде. РСФСР Мәдәният министрлыгы һәм мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы Үзәк Комитетының, ТАССР Министрлар Советы каршындагы Кинематография буенча дәүләт комитетының Мактау грамоталарына лаек булды. 2013 елда «Ел хатын-кызы» зона конкурсында «Өченче буын герое» номинациясендә җиңү яулады. Хәер, ветеранның барлык бүләкләрен санап чыгарга да шактый вакыт кирәк булыр иде. Кызганыч, тормыш иптәше Федор Семенович якты дөньядан иртәрәк китеп барды. Рәшидә Шакир кызы өчен иң зур шатлык балаларының, оныкларының исән-сау булып, тигезлектә гомер итүләре. Ул ялгыз түгел. Өч улы Рифат, Наил, Рамил төрле юнәлештә югары уку йортларын тәмамладылар, үз эшләрендә алыштыргысыз саналалар. Киленнәреннән дә уңды, өчесе дә «әни» дип кенә торалар.

– Тормышны бик яраттым. Эштән курыкмадым. Матур яшәдек, – ди Рәшидә апа.

Әминә МИҢНУЛЛИНА.
Буа районы

Укучылар токмач та кисте.

Өлкәннәрне җырлап каршы алдылар.